**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ИСКЕ ИЛДЕРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№63 02.02.2018 ел

**Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы Рәисенең 2017 елгы социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2018 елга фараз турында хисабы.**

Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы Рәисенең 2017 елгы социаль – икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2018 елга фараз турындагы хисабын тыңлап һәм фикер алышып. Депутатлар билгеләп үткәнчә, авыл җирлеге Советы эшчәнлеге 2017 елда авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә, «РФда җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 6.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Иске Илдерәк авыл Советы тарафыннан билгеләнгән компетенция һәм вәкаләтләр нигезендә карар:

1. Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы Рәисе В.К. Альметкинның 2017 елда авыл җирлегенең социаль – икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2018 елга фараз турында хисабын игътибарга алырга.
2. 2018 елда авыл җирлеген социаль – икътисади үстерү стратегиясенең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала.
3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә.
4. Халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә.
5. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.
6. Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.
7. Авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә һәм хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.
8. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatar.ru.
9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Совет рәисе, Глава
Иске Илдерәк авыл җирлеге башлыгы: В. Альметкин.

СОВЕТ СТАРОИЛЬДЕРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО